МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.03.2023 Казан ш № 180

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгын Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәү турында белешмә формасын һәм аны электрон формада тәкъдим

итү форматынраслау турында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның сигезенче, тугызынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзегәнчегә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага салым органы белешмәсе, ул Учреждениедә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар буенча үтәлмәгән бурычның булмавын расларга тиеш»;

«Килешү төзелгәнчегә кадәр 30 календарь көннән иртәрәк булмаган датага Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү түләү вакыты узган бурычларының булмавы турында җитәкче һәм баш бухгалтер, вәкаләтле башка зат тарафыннан имзаланган белешмә»;

6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Килешү төзелгәнче 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

Тәртипнең 1 нче кушымтасында 1-9 пунктларның «Субсидия күләмен исәпләү» графасында «Татарстан Республикасы Президенты карары» сүзен «Татарстан Республикасы Рәисе карары» сүзләре белән алмаштырырга.

Министр Э.Ә. Зарипова

ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА